| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2020 Казан шәһәре № 75-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламентын раслау турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 11 февралендәге 90 номерлы карарын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламентын (алга таба – Регламент) (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруны турыдан-туры тәэмин итүче вазыйфаи затларына Регламент нигезләмәләренә таянып эш итәргә.

3. Ветеринария эшчәнлеген оештыру бүлегенә Регламентны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Хөкүмәте Рәсми порталында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш

ветеринария идарәсе сайтындагы «ТР МК Баш ветеринария идарәсе норматив хокукый актлары» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

4. Хокук бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасы
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г.Хисаметдинов

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Баш
ветеринария идарәсенең 2020
елның 22 маендагы 75-од
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдаланучга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламенты

# 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАЛЫШЫ

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда (алга таба – дәүләт функциясе, дәүләт күзәтчелеге) административ процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Әлеге Регламентта кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ БАШКАРМА ОРГАНЫ АТАМАСЫ

1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе (алга таба – ТР МК Баш ветеринария идарәсе) дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручылар – ТР МК Баш ветеринария идарәсенең территориаль бүлекләре (алга таба – Бүлек), ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы, башлык урынбасары боерыгы нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар (алга таба – вазыйфаи затлар, җаваплы башкаручылар).

1.4. «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры) мәгълүмат ТР МК Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан кертелә.

1.5. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда ТР МК Баш ветеринария

идарәсе вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы Прокуратурасы органнары (алга таба – прокуратура органнары), экспертлар һәм эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар белән хезмәттәшлек итә.

ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫ ҖАЙГА САЛУЧЫ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.6. Дәүләт күзәтчелеге түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №1, 1 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җинаять кодексы (алга таба – РФ Җинаять кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, №25, 2954 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №19, 2060 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №1, 26 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 498-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, №53, 8424 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №28, 3706 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия

Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №19, 2825 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №44, 6127 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә дә, әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 №17, 2418 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, №8, 1239 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы күрсәтмәсе (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №18, 2647 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләре» 1995 елның 4 декабрендәге 13-7-2/469 номерлы боерыгы («Российские вести», 1996, 22 февраль, №35, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының «Дәүләт контролен (күзәт-челеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26

декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законны гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 27 мартындагы 93 боерыгы (алга таба – Россия Генераль прокуратурасының 93 номерлы боерыгы) (Законность, №5, 2009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, басылып чыгу номеры: 0001201703210041);

Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Ветеринария буенча теркәлә торган документларны рәсмиләштерү эшен оештыруда ветеринария кагыйдәләрен, ветеринария буенча теркәлә торган документларны электрон формада рәсмиләштерү тәртибен һәм ветеринария буенча теркәлә торган документларны кәгазьдә рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 27 декабрендәге 589 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының 589 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 30 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201612300100);

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, №5, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2020, №4, 0136 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 24.04.2012, №31, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру

тәртибе (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 1275 номерлы карары белән расланган Тәртип)(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2020, №12, 0285 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 11 февралендәге 90 номерлы карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 90 номерлы карары) («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2020, №15, 0413 статья);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 февралендәге 150 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру һәм аларда хайваннарны тоту нормасы (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 150 номерлы карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2020, №19, 0545 статья).

ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕНЕҢ ПРЕДМЕТЫ

1.7. Юридик затлар, аларның җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре, шул исәптән 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торганнары да (алга таба – юридик затлар, шәхси эшкуарлар), һәм физик затлар тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру процессында, хайваннарны мәдәни-тамаша максатларында (зоопаркларда, зообакчаларда, циркларда, зоотеатрларда, дельфинарийларда, океанариумнарда) һәм ярымирекле шартларда яки төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә ясалма оештырылган тереклек мохитендә, ирексезлек шартларында асрала торган кыргый, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына кертелгән төрләргә караган һәм (яки) Россия Федерациясе халыкара килешүләре нигезендә саклана торган хайваннарны асрау һәм алардан файдалану таләпләреннән (алга таба – зарури таләпләр) тыш, йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә 498-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше дәүләт күзәтчелеге предметы булып тора.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт күзәтчелеге әлеге Регламентта каралган тәртиптә, 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында билгеләнгән тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ТР МК БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ ӨЧЕН ХОКУКЛАР, БУРЫЧЛАР ҺӘМ ЧИКЛӘҮЛӘР

1.8. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә түбәндәге хокукка ия:

1) юридик затлар һәм физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар тарафыннан хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларның таләпләре үтәлешенә бәйле мәгълүматны һәм документларны соратырга һәм алырга;

2) юридик затлар һәм физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар тарафыннан хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларның таләпләре үтәлүен тикшерергә, тикшерү нәтиҗәләре буенча тиешле актлар төзергә;

3) әлеге оешмалар тарафыннан хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларның таләпләре үтәлүен тикшерү максатларында, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хайваннар тотучы оешмаларга каршылыксыз үтеп керергә һәм тикшерергә;

4) юридик затларга һәм физик затларга, шулай ук шәхси эшкуарларга хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларның таләпләре бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмәләр бирергә һәм бирелгән күрсәтмәләр үтәлешен тикшерергә;

5) хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларның таләпләре бозылуга бәйле хокук бозуларны чикләргә;

6) хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларның таләпләре бозылуга бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, әлеге административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм аларны бетерү буенча чаралар күрергә;

7) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда гражданнардан хайваннарны алырга;

8) административ хокук бозулар турында эшләр кузгату яки җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату мәсьәләләрен хәл итү өчен, хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларның таләпләре бозылуга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрергә;

9) юридик затның, шәхси эшкуарның зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләреннән аңлатмалар алырга;

10) тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә дә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә

органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;

11) үзенә карата тикшерү уздырыла торган оешма белән граждани-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган экспертларны, эксперт оешмаларын тикшерүләр уздыруга җәлеп итәргә.

1.9. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә бурычлы:

1) зарури таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, үзләренә карата тикшерү уздырыла торган юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

3) ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү билгеләнүенә бәйле рәвештә аны уздыру турындагы күрсәтмәсе нигезендә тикшерү уздырырга;

4) тикшерүне фәкать хезмәт бурычларын үтәү вакытында гына, күчмә тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) күчермәсен һәм, әлеге Регламентның 2.19 пунктының 2 пунктчасында каралган очракта, тикшерү уздыруны килештерү турындагы документ күчермәсен күрсәтеп кенә уздырырга;

5) юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәскә;

6) тикшерү үткәргәндә катнаша торган юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагыла торган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозулар буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә әлеге чараларның бозуларның катлаулылыгына, аларның кешеләрнең гомере, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), дәүләт иминлеге өчен, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе өчен потенциаль куркыныч булуына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук

гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез рәвештә чикләнүенә юл куймаска;

10) юридик затлар, шәхси эшкуалар тарафыннан шикаять белдерелгәндә, үз гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

11) тикшерү уздыруның 294-ФЗ номерлы федераль законда, 473-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән срокларын сакларга;

12) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә;

13) күчмә тикшерү уздыра башлар алдыннан юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиленең гозере буенча аларны тикшерү уздыруга нигез булган әлеге Регламент кушымталары белән таныштырырга;

14) юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу теркәргә.

1.10. ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) әгәр бу таләпләр ТР МК Баш ветеринария идарәсе вәкаләтләренә карамаса, ТР МК Баш ветеринария идарәсе исеменнән гамәл кылучы вазыйфаи затлар буларак, зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләр үтәлешен, шулай ук кулланылышы Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актларда билгеләнгән зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

4) кешеләрнең гомере, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), дәүләт иминлеге өчен зыян салыну, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү нигезендә уздырылган тикшерү очрагыннан тыш, тикшерү уздырганда юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очакта, планлы яки планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга;

5) әгәр алар тикшерү объектлары булып тормаса яисә тикшерү предметына карамаса, документлар, мәгълүматлар, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның нөсхәләрен алырга;

6) продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу өчен әлеге үрнәкләрне, пробаларны алу турында беркетмәләрне билгеләнгән рәвешендә рәсмиләштермичә һәм илкүләм стандартларда, үрнәкләрне, пробаларны алу кагыйдәләрендә һәм аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу методларында, техник регламентларда яисә алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка

норматив техник документларда һәм тикшеренүләр, сынаулар, үлчәмнәр алу кагыйдәләрендә һәм методларында билгеләнгән нормалардан артып китүче санда алырга;

7) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка төрле серне тәшкил итүче мәгълүматларны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

8) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән вакытларын арттырырга;

9) юридик затларга, шәхси эшкуарларга алар хисабыннан контроль чараларны үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә;

10) юридик заттан, шәхси эшкуардан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерү үткәрә башлаган датага кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә. ТР МК Баш ветеринария идарәсе, тикшерү үткәрү турында күрсәтмә (боерык) кабул иткәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЗАТЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.11. Тикшерү уздырылганда юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең хокуклары:

1) тикшерүне үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) ТР МК Баш ветеринария идарәсеннән, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагыла торган һәм бирелеше 294-ФЗ номерлы федераль законда каралган мәгълүматны алырга;

3) документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында ТР МК Баш ветеринария идарәсенә алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматны ТР МК Баш ветерианрия идарәсенә үз ихтыяры белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу, алар белән, шулай ук ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешү яки килешмәү турында күрсәтергә;

6) тикшерү уздырганда ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.12. Тикшерү уздырылганда юридик затларның, шәхси эшкуарларның бурычлары:

1) күчмә тикшерүгә аннан алда булып узган документар тикшерү сәбәпче булмаса, күчмә тикшерү үткәрә торган ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларына күчмә тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән танышып чыгу мөмкинлеген бирергә, шулай ук күчмә тикшерү үткәрә торган ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларына һәм күчмә тикшерү уздырганда катнаша торган экспертларга, эксперт оешмалары вәкилләренә хайваннар тотыла торган территориягә үтеп керү мөмкинлеген тудырырга;

2) юридик затлар юридик зат җитәкчеләренең, башка вазыйфаи затларының яисә вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә; шәхси эшкуарлар үзләре катнашырга яисә зарури таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыруга һәм уздыруга җаваплы булган вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә тиеш;

3) дәлилле мөрәҗәгать алынганнан соң ун эш көне эчендә мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны ТР МК Баш ветеринария идарәсенә җибәрергә.

## ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.13. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

тикшерүләрне гамәлгә ашырганда:

1) Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча 2 нөсхәдә рәсмиләштерелгән тикшерү акты;

2) тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) уздырылган күчмә тикшерү турында язу (тикшерүләрне исәпкә алу журналының формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

3) 294-ФЗ номерлы федераль законның $13^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

тикшерү барышында зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта:

4) ачыкланган бозуларны бетерү турында тикшерү актына кушымта булып торучы һәм әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән күрсәтмә;

ачыкланган хокук бозуларда җинаять составы билгеләре булган очракта:

5) гаепле затларны җинаять җаваплылыгына тарту турында карар кабул итү өчен хокук саклау органнарына җибәрелгән гариза һәм тикшерү материаллары;

юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары гамәлгә ашырылганда:

6) зарурлык булган очракта, планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү өчен, ачыкланган хокук бозулар турында мәгълүмат белән ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына (ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасарына) дәлилләнгән күрсәтмә;

7) әлеге Регламентның 3.3, 3.4 пунктлары нигезендә юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән һәм әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелгән зарури таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү.

ТР МК Баш ветеринария идарәсенә гражданнардан, оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) алынган мәгълүмат дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру нигезе булган очракта, дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең урнашу урыны һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсенә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420111, Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36, а/т 74.

ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлекләренең адреслары һәм телефоннары 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче ТАБЛИЦА – ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлекләренең адреслары һәм телефоннары

| ТР МК Баш ветеринария идарәсенең территориаль бүлеге атамасы | Адрес | Телефон |
|---|---|---|
| ТР МК Баш ветеринария идарәсенең Алексеевск территориаль бүлеге | 422980, Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 | 8 (843) 425-24-26 |
| ТР МК Баш ветеринария | 423452, Татарстан Республикасы, Әлмәт | 8 (855) 332-17-61 |

| | | |
|---|---|---|
| идарәсенең Әлмәт территориаль бүлеге | шәһәре, Клара Цеткин урамы, 54а | |
| ТР МК Баш ветеринария идарәсенең Апас территориаль бүлеге | 422350, Татарстан Республикасы, Апас районы, Апас ш.т.п., Совет урамы, 5 | 8 (843) 762-15-63 |
| ТР МК Баш ветеринария идарәсенең Казан территориаль бүлеге | 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36 | 8 (843) 762-15-63 |
| ТР МК Баш ветеринария идарәсенең Яр Чаллы территориаль бүлеге | 423806, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, ГЭС поселогы, Муса Җәлил проспекты, 56 | 8 (855) 270-15-83 |
| ТР МК Баш ветеринария идарәсенең Түбән Кама территориаль бүлеге | 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Актүбә урамы, 6А | 8 (855) 542-50-44 |
| ТР МК Баш ветеринария идарәсенең Саба территориаль бүлеге | 422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Завод урамы, 19 | 8 (843) 622-53-78 |

2.2. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсенең территориаль бүлекләренең эш графигы: дүшәмбе – җомга 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр. Төшке аш: 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр. Ял көннәре: шимбә, якшәмбе. Бәйрәм алды көннәрендә эш көне бер сәгатькә кыскара.

2.3. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең белешмә телефоннары:

ТР МК Баш ветеринария идарәсенең башлыгының кабул итү бүлмәсе: 8 (843) 221-77-47, 221-77-49;

ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгының дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру мәсьәләләрен алып баручы урынбасары: 8 (843) 221-77-50;

ТР МК Баш ветеринария идарәсенең дәүләт ветеринария инспекциясе бүлегенең белешмәләр һәм консультацияләр өчен телефон: 8 (843) 221-77-51;

2.4. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайты: http://guv.tatarstan.ru к

2.5. ТР МК Баш ветеринария идарәсенә электрон мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен электрон почта адресы: guv@tatar.ru.

2.6. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре, шул исәптән аны гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүмат ТР МК Баш ветеринария идарәсе һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсенең территориаль бүлекләренә телефон аша мөрәҗәгать итү, ТР МК Баш ветеринария идарәсе белгечләренә шәхсән мөрәҗәгать итү, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтыннан файдаланып, ТР МК Баш ветеринария идарәсенә почта аша язмача, электрон почта ярдәмендә электрон рәвештә мөрәҗәгать итеп алынырга мөмкин.

2.7. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми (http://guv.tatarstan.ru) сайтында, ТР МК Баш ветеринария идарәсендә һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлекләрендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру урыны буенча мәгълүмат такталарында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

- ТР МК Баш ветеринария идарәсенең һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлекләренең урнашу урыны турында мәгълүмат, эш графигы, телефон һәм факс номерлары, дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат бирә ала торган вазыйфаи затларның электрон почта адресы;

- әлеге Регламент;

- планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы;

- ел саен ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан раслана торган зарури таләпләр бозылуны профилактикалау программасы;

- дәүләт күзәтчелегенең тикшерү предметы аларның үтәлешен бәяләүдән гыйбарәт булган зарури таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актларның яки аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

- зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шулай ук зарури таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар турында мәгълүмат, семинарлар һәм конференцияләр үткәрелүе, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре турында белешмәләр, бүтән ысуллар белән урнаштырылган бүтән мәгълүматлар турында белешмәләр. Зарури таләпләр үзгәртелгән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләрдәге зарури таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук зарури таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, зарури оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

- дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү (елга бер мәртәбәдән ешрак түгел), юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар тарафыннан зарури таләпләр бозылуына юл куелмау максатларында күрелергә тиешле чаралар буенча киңәшләр белән, мондый бозуларның иң еш очрый торган очракларын да күрсәтеп.

Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру турындагы мәгълүмат үзгәртелгәндә, ул яңартыла.

2.8. Телдән мөрәҗәгатькә җавап кичекмәстән, мөрәҗәгать иткәннән соң ук бирелә, язмача мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта буенча мөрәҗәгатькә җавап, тиешенчә, күрсәтелгән почта адресына яки электрон адреска, әлеге мөрәҗәгать ТР МК Баш ветеринария идарәсендә теркәлгән вакыттан башлап календарь көннәрендә исәпләнә торган утыз көнлек срокта җибәрелә һәм анда куелган сорауларга җаваплар, башкаручының фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры булырга тиеш. Җавапка ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы кул куя.

Телефон аша мөрәҗәгать кабул иткән ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затының куелган сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап бирү мөмкинлеге булмаса, телефон аша алынган мөрәҗәгать башка вазыйфаи затка

адресланырга (күчерелергә) тиеш яисә мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры турында хәбәр ителә.

ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ БУЕНЧА ЧАРАЛАРНЫ ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРДАН, ФИЗИК ЗАТЛАРДАН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ ЯРАМАГАНЛЫГЫ

2.9. Дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар үткәргән өчен юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан, физик затлардан түләү алынмый, шул исәптән тикшерүләрне үткәрү өчен җәлеп ителгән очракта, экспертларның һәм эксперт оешмаларының хезмәтләре өчен дә.

ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ҮТӘҮ СРОГЫ

2.10. Һәр тикшерүне (документар (планлы яки планнан тыш), шулай ук күчмә (планлы яки планнан тыш) үткәрү вакыты егерме эш көненнән артмаска тиеш.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

2.11. Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең планлы күчмә тикшерү үткәрә торган вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк булган чорга түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – илле сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

2.12. Кече эшкуарлык субъектына карата планлы күчмә тикшерү үткәрелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу зарурлыгы килеп туган очракта, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытка, ләкин иң күбе ун эш көненнән артмаган чорга туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору чоры гамәлдә булганда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бүлмәләрендә, бүтән объектларында ТР МК Баш ветеринария идарәсенең әлеге тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатып торыла.

2.13. Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затка карата тикшерү (документар, күчмә) уздыру вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе өчен аерым билгеләнә, бу вакытта тикшерү уздыруның гомуми вакыты алтмыш эш көненнән артык була алмый.

2.14. Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларын тикшерү сроклары 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясы таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

## ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.15. Планлы тикшерүләр ТР МК Баш ветеринария идарәсе, ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлеге тарафыннан эшләнә һәм раслана торган юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнары (алга таба – ел саен уздырыла торган тикшерүләр планы) нигезендә уздырыла.

2.16. Ел саен уздырыла торган тикшерүләр планы 294-ФЗ номерлы федераль законга һәм РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарына ярашлы рәвештә эшләнә.

2.17. ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан расланган еллык планнар «Интернет» челтәрендә ТР МК Баш ветеринария идарәсе рәсми сайтында урнаштырыла.

2.18. Планлы тикшерүне ел саен уздырыла торган тикшерүләр планына кертү өчен әлеге көннән соң өч ел вакыт узып китүе нигез булып тора:

1) юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алган көннән башлап;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән башлап;

3) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тиешле өлкәдә вәкаләтле дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында тапшырылган хәбәр нигезендә, әлеге хәбәрне тапшыруны таләп итә торган эшләр башкарылган яисә хезмәтләр күрсәтелгән очракта, эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаган көннән башлап.

Әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкача билгеләнмәгән булса, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 4 статьясы нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертелгән, үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата тикшерүләр, тикшерүләрне уздыру өчен гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салу яки мондый зыян салыну, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу хәтәре нигез булган очраклардан тыш, 2020 елның 1 апреленнән башлап 31 декабренә кадәр уздырылмый.

2.19. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш тикшерү үткәрү нигезләре:

1) зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очрагын юкка чыгару турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәү вакытының узып китүе;

2) ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затының дәлилле күрсәтмәсе, – юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә үткәрелгән контрольлек чаралары, гражданнардан, шулай ук шәхси эшкуарлардан, юридик

затлардан ТР МК Баш ветеринария идарәсенә түбәндәге фактлар турында юлланган мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларны карау яки беренчел тикшерү нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсендә:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килүе;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салынуы, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салынуы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе нигезендә кабул ителгән ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы күрсәтмәсе (боерыгы).

2.20. Физик затларга карата дәүләт күзәтчелеге түбәндәгеләрне оештыру һәм үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла:

а) планлы (рейдлы) тикшерүләр;

б) планнан тыш документар һәм (яки) күчмә тикшерүләр.

2.21. ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан расланган план (рейд) йөкләмәсе физик затка карата планлы (рейдлы) тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора, ул зарури таләпләр бозылу билгеләре турындагы мәгълүмат нигезендә төзелә:

1) гражданнарның, шулай ук шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләреннән һәм гаризаларыннан, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматыннан – хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары таләпләренең бозылуы турында;

2) тикшерү, шулай ук зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмәләр үтәлешен тикшерү актларында, башка төр башкарма документларда булган;

3) үз вәкаләтләре кысаларында ТР МК Баш ветеринария идарәсе гамәлгә ашыра торган мониторингны уздырылганда алынган.

2.22. Физик затка карата планнан тыш документар һәм (яки) күчмә тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очрагын юкка чыгару турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең физик зат тарафыннан үтәлү вакытының узуы;

хайваннар тарафыннан гражданнарның гомеренә яки сәламәтлегенә һәм (яки) хайваннарга зыян салыну куркынычы барлыкка килүе яки зыян салынуы турында белешмәләрне үз эченә алган гражданнарның, шулай ук шәхси эшкуарларның, юридик затларның ТР МК Баш ветеринария идарәсенә алынган

гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан мәгълүмат, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларындагы мәкаләләр нигез була ала;

планлы (рейдлы) тикшерүләр уздырганда зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очраклары (ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы, башлык урынбасары карары буенча).

2.23. ТР МК Баш ветеринария идарәсенә мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 2.19 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмый. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, аларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан бары тик бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторлаштырылуын күздә тоткан мәгълүмат-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булуы шарты белән генә, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә ала.

2.24. Әлеге Регламентның 2.19 пунктында күрсәтелгән фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карап тикшергәндә элегрәк килгән, охшаш мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карап тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.25. Зарури таләпләр бозылуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, әлеге Регламентның 2.19 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек белешмәләр булмаганда, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрелергә мөмкин. Алынган мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрү барышында гаризаны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән, мәгълүмат тапшырган затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән тәртиптә) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси эшкуарның ТР МК Баш ветеринария идарәсе карамагында булган документлары карап тикшерелә.

Кирәк булганда, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә һәм әлеге затларга мәгълүмат бирү һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары таләпләрен үтәү бурычларын йөкләмичә генә контрольлек чаралары үткәрелә.

Беренчел тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшкуардан алынган мәгълүматка аңлатмалар соратылырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.

2.26. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, әлеге Регламентның 2.19 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек күләмдә белешмәләр алынганда, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты, әлеге Регламентның 2.19 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле күрсәтмә әзерли. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшкуарны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.27. ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) карары буенча, әгәр тиешле тикшерүне башлаганнан соң, аны оештыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып ялган белешмәләр булуы ачыкланса, беренчел тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

2.28. ТР МК Баш ветеринария идарәсе, әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелсә, гражданиннан, шулай ук юридик заттан, шәхси эшкуардан, әлеге затлардан килгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә ТР МК Баш ветеринария идарәсе тоткан чыгымнарны түләттерү турында судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.29. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан әлеге Регламентның 2.19 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлекләре гамәлгә ашырыла торган урын буенча, прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.

Юридик затны, шәхси эшкуарны планнан тыш күчмә тикшерүне прокуратура органы белән килештерү турындагы гариза рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

2.30. Әгәр юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очракларын юкка чыгару турындагы күрсәтмәне үтәү вакыты узу планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып торса, ул очракта мондый тикшерүнең предметы булып бары тик ТР МК Баш ветеринария идарәсе биргән күрсәтмә үтәлеше генә тора ала.

## ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.31. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенең 4 пункты нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары булып түбәндәгеләр тора:

а) вазыйфаи регламентларында дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру вәкаләтләре каралган җитәкчеләр һәм аларның урынбасарлары;

б) структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, шулай ук вазыйфаи регламентларында дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру вәкаләтләре каралган Татарстан Республикасының башка дәүләт граждан хезмәткәрләре.

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ЗАКОННАРЫН БОЗГАН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРНЫҢ, ФИЗИК ЗАТЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.32. Тикшерүләр уздырганда юридик затлар юридик затларның җитәкчеләренең, башка вазыйфаи затларының яисә вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә тиеш; шәхси эшкуарлар үзләре катнашырга яисә зарури

таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыруга һәм уздыруга җаваплы булган вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә тиеш.

2.33. 294-ФЗ номерлы федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез рәвештә каршы төшкән, тикшерүләрне үткәрүдән читләшкән һәм (яки) билгеләнгән чорларда зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында ТР МК Баш ветеринария идарәсе күрсәтмәләрен үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

2.34. Тикшерү барышында ТР МК Баш ветеринария ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан РФ Җинаять кодексында җинаять дип танылган торган хайваннарга карата рәхимсез мөгамәлә очрагы ачыкланса, тикшерү актында тиешле язма теркәлә һәм акт күчермәсе билгеләнгән компетенция кысаларында чаралар күрү өчен хокук саклау органнарына җибәрелә.

2.35. ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затының законлы эшчәнлегенә комачаулау турындагы белешмәләр булган очракта, физик затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

## 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРГА, ФИЗИК ЗАТЛАРГА КАРАТА БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга, физик затларга карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге, тиешле таләпне билгели торган норматив хокукый актларны күрсәтеп, 2 нче таблицада китерелде.

2 нче ТАБЛИЦА – Юридик затларга, шәхси эшкуарларга, физик затларга белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| Контрольдә тотылучы барлык объектлар | |
| Хайваннар тотуга карата гомуми таләпләр үтәлеше | 498-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы |
| Кешеләрне хайваннардан алар гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерүдән саклауны тәэмин итә торган аерым шартларга карата таләпләр үтәлеше | 498-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясы |
| Хайваннарны рәхимсез мөгамәләдән яклауны тәэмин итү таләпләре үтәлеше | 498-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясы |
| Хайваннар белән рәхимсез мөгамәлә пропагандалауны тыю таләпләренең | 498-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы |

| | |
|---|---|
| үтәлеше | |
| Юридик затлар, шәхси эшкуарлар | |
| Эш хайваннарын тоту һәм алардан файдалану таләпләренең үтәлеше | 498-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы |
| Хайваннар өчен приютларга карата таләпләр үтәлеше | 498-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясы, ТР Министрлар Кабинетының 150 номерлы карары белән расланган Тәртип |
| Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга карата таләпләр үтәлеше | 498-ФЗ номерлы федераль законның 17, 18 статьялары, ТР Министрлар Кабинетының 1275 номерлы карары белән расланган Тәртип |
| Физик затлар | |
| Йорт хайваннарын тотуга карата таләпләр үтәлеше | 498-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясы |

3.2. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләр бозылу очракларын кисәтү, зарури таләпләр бозылуга сәбәпче булган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында, ТР МК Баш ветеринария идарәсе, ел саен раслана торган бозуларны кисәтү программасына туры китереп, зарури таләпләр бозылуны кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.3. Зарури таләпләр бозылуны профилактикалау максатларында, ТР МК Баш ветеринария идарәсе 294-ФЗ номерлы федераль законның 8.2 статьясының 5-7 өлешләрендә билгеләнгән очракларда һәм тәртипкә ярашлы рәвештә зарури таләпләр бозылуның ярамаганлыгы турында кисәтү бирә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән чорда ТР МК Баш ветеринария идарәсенә хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан карау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ТР МК Баш ветеринария идарәсенә мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары белән расланган Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. ТИКШЕРҮ БАРЫШЫНДА ЮРИДИК ЗАТ, ШӘХСИ ЭШКУАР, ФИЗИК ЗАТ ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

4.1. Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар, физик зат тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелде.

3 нче ТАБЛИЦА – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен дәүләт күзәтчелеге объекты тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| Тикшерү вакытында юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1. Юридик затның яки шәхси эшкуарның гамәлгә кую һәм теркәү документлары | РФ Гражданлык кодексының 52 статьясы; «Акционерлык җәмгыятьләре турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясы; «Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы; «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы; Федераль салым хезмәтенең 2012 елның 25 гыйнварындагы ММВ-7-6/25@ номерлы һәм 2016 елның 12 сентябрендәге ММВ-7-14/481@ номерлы боерыклары |
| 2. Физик затның шәхесен таныклаучы документлар | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданины паспорты, Россия Федерациясе гражданины паспортының бланк үрнәге һәм тасвирламасы турында нигезләмә раслау турында» 1997 елның 8 июлендәге 828 номерлы карары; «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясы |
| 3. Алдагы тикшерүләрнең актлары | Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгына 3 нче кушымта |
| 4. Алдагы тикшерүләр нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләр үтәлеше турындагы документлар (хисап) | |
| 5. Зарури таләпләр нигезендә саклык йөкләмәсе таләпләрен үтәү (саклау) буенча тикшерә торган зат күрә торган чараларны теркәгән документлар | |

| | |
|---|---|
| 6. 1 номерлы формада ветеринария таныклыгы;<br>4 номерлы формада ветеринария белешмәсе | Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының 589 номерлы боерыгы |
| 7. Юридик затка, шәхси эшкуарга ТР МК Баш ветеринария идарәсе үткәрә торган тикшерүләрне исәпкә алу журналы (ул юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта) | Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче боерыгына 4 нче кушымта |
| 8. Юридик яки физик зат, шулай ук шәхси эшкуар мәнфәгатьләрен яклау буенча ышаныч кәгазе | Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 185 статьясы |
| 9. Махсуслаштырылган оешма хезмәткәре таныклыгы | ТР Министрлар Кабинетының 1275 номерлы карары белән расланган Тәртипкә 1 нче кушымта |
| 10. Хуҗасыз хайваннарны тотып алу акты | ТР Министрлар Кабинетының 1275 номерлы карары белән расланган Тәртипкә 2 нче кушымта |
| 11. Хуҗасыз хайванны исәпкә алу картасы | ТР Министрлар Кабинетының 1275 номерлы карары белән расланган Тәртипкә 3 нче кушымта |
| 12. Хуҗасыз хайванны чыгарып җибәрү акты | ТР Министрлар Кабинетының 1275 номерлы карары белән расланган Тәртипкә 4 нче кушымта |
| 13. Тотып алынган хайванны карап чыгу һәм приютка тапшыру акты | ТР Министрлар Кабинетының 150 номерлы карары белән расланган Тәртипкә 1 нче кушымта |
| 14. Приютка хайваннарның килүен һәм китүен исәпкә алу журналы | ТР Министрлар Кабинетының 150 номерлы карары белән расланган Тәртипкә 2 нче кушымта |
| 15. Этне теркәү турында таныклык | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 24 маендагы 298 номерлы карары<br>«Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү тәртибен раслау турында» |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ДӘ ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ СОСТАВЫ

5.1. Юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата дәүләт күзәтчелеге планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла, алар документар һәм (яки) күчмә тикшерү уздыру, зарури таләпләр бозылуны профилактикалау чараларын оештыру һәм уздыру (әлеге Регламентның 3.2-.3.4 пунктлары), ачыкланган бозуларның нәтиҗәләрен чикләү һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрү, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыру формасында уздырыла.

Физик затларга карата дәүләт күзәтчелеге түбәндәгеләрне оештыру һәм үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла:

а) планлы (рейдлы) тикшерүләр;

б) планнан тыш документар һәм (яки) күчмә тикшерүләр.

5.2. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

планлы тикшерүләр уздыруны планлаштыру;

юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздыру;

юридик затка, шәхси эшкуарга планлы күчмә тикшерү уздыру;

юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру;

юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыру;

физик затларга карата дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру.

5.3. Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата дәүләт күзәтчелеге әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.4. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруның Блок-схемасы әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

5.5. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруны туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәт ителә.

## «ПЛАНЛЫ ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ»<br>АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.6. Административ процедураны башлап җибәрү өчен еллык планны әзерләү вакытының килеп җитүе нигез булып тора.

5.7. Тикшерүләр планы Бүлек тарафыннан 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә эшләнә. Еллык планны әзерләү, шул исәптән аны прокуратура органнарына тапшыру һәм прокуратура органнары белән килештерү тәртибе һәм сроклары, шулай ук еллык планның бертип формалары РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси

эшкуарларга карата планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән.

Планлы тикшерүне еллык планга кертү өчен әлеге Регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

Тикшерүләрнең еллык планын әзерләгәндә җаваплы башкаручы, кирәк булганда, аны төзү өчен кирәкле документларны һәм (яки) әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендә тиешле мәгълүматны сората һәм билгеләнгән тәртиптә ала.

5.8. Ел саен үткәрелә торган тикшерүләр планын әзерләү буенча җаваплы башкаручы ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан расланган еллык планны ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштыруны оештыра.

Үтәү вакыты: Татарстан Республикасы Прокуратурасы сайтында ел саен үткәрелә торган бердәм еллык тикшерүләр планы урнаштырылганнан соң 5 эш көне узганчы.

5.9. РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында билгеләнгән очракларда, раслый торган документлар, мисал өчен, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан дәүләт теркәве турында, юридик затның, шәхси эшкуарның бетерелүе (реестрдан төшереп калдырылуы) турында язу булган очракта, еллык планга үзгәрешләр кертү рөхсәт ителә.

Еллык планга үзгәрешләр кертү ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы боерыгы белән башкарыла. Кертелгән үзгәрешләр турындагы белешмәләр билгеләнгән тәртиптә тиешле прокуратура органына аларны керткән көннән башлап 3 эш көне эчендә җибәрелә һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштырыла.

## «ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.10. «Планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасын башлау өчен еллык план нигезендә юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы документар тикшерүне гамәлгә ашыру срокларының килеп җитүе нигез булып тора.

«Планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасы түбәндәге административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

- тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;
- тикшерү уздыру турында күрсәтмә (боерык) рәсмиләштерү;
- юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү үткәрү хакында хәбәр итү;
- тикшерүне үткәрү;
- тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү;

- тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру.

ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛГАН ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.11. Еллык план нигезендә үз компетенцияләре кысаларында тикшерү үткәрүче ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлекләре башлыклары юридик затка, шәхси эшкуарга карата тикшерү үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны (алга таба – җаваплы башкаручы) билгели.

Үтәү вакыты: тикшерү башланганчы ун эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.12. Җаваплы башкаручы:

- 294-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү үткәрү турында күрсәтмә (боерык) проектын әзерли;

- күрсәтмә (боерык) проектын имза салу өчен ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Үтәү вакыты: тикшерү башланганчы җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга карата документар тикшерү үткәрү турында ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган күрсәтмә (боерык).

ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.13. Җаваплы башкаручы планлы тикшерүне үткәрә башлау турында ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) күчермәсен, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы җибәрү юлы белән һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ТР МК Баш ветеринария идарәсенә элегрәк тапшырылган булса, яисә башка үтемле ысул белән юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү үткәреләчәге хакында хәбәр итә.

Юридик затка, шәхси эшкуарга – үзкөйләнешле оешма әгъзасына карата тикшерү үткәрелгән очракта, җаваплы башкаручы шулай ук, планлы документар

тикшерү үткәргәндә аннан вәкил катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үзкөйләнешле оешмага хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерү башланганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән күрсәтмә (боерык) күчермәсе һәм үзкөйләнешле оешмага (үзкөйләнешле оешма әгъзасына тикшерү уздырылган очракта) җибәрелгән хәбәр.

ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ

5.14. Планлы документар тикшерү ТР МК Баш ветеринария идарәсе урнашкан урыны буенча үткәрелә.

Тикшерү уздырган вакытта вазыйфаи затлар тарафыннан иң беренче нәүбәттә юридик затның, шәхси эшкуарның ТР МК Баш ветеринария идарәсе карамагында булган документлары, шул исәптән алдагы тикшерүләрнең актлары, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материаллары һәм әлеге юридик затка, шәхси эшкуарга карата гамәлгә ашырылган дәүләт күзәтчелеге нәтиҗәләре турында башка документлар карала.

Җаваплы башкаручы, тикшерү уздыру турында боерык кабул ителгәннән соң, кирәкле документларны юридик заттан, шәхси эшкуардан һәм (яисә) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратырга хокуклы.

Документар тикшерү уздырылганда ТР МК Баш ветеринария идарәсе юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук аның тарафыннан башка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

Әгәр документар тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган документларда хаталар булуы һәм (яисә) каршылыклар, яисә бу документларда булган мәгълүматларның ТР МК Баш ветеринария идарәсе карамагында булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы:

- юридик затка, шәхси эшкуарга, белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат белән һәм ун эш көнендә язмача рәвештә кирәкле аңлатмаларны тапшыруын таләп итеп, хат (дәлилле мөрәҗәгать) әзерли;

- хатны (дәлилле мөрәҗәгатьне), имзалау өчен, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына (башлык урынбасарына) юллый;

- имзаланганнан соң хатны (дәлилле мөрәҗәгатьне) юридик зат, шәхси эшкуар адресына, кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы хат итеп яисә үтемле башка ысул белән (факсимиль элемтә, электрон почта, кулга алу турында белдереп, кулга тапшырып) җибәрә.

Дәлилле мөрәҗәгать алынган көннән башлап ун эш көне эчендә юридик зат, шәхси эшкуар рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны ТР МК Баш ветеринария идарәсенә җибәрергә тиеш.

ТР МК Баш ветеринария идарәсенә тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документларда булган

белешмәләрнең ТР МК Баш ветеринария идарәсе карамагындагы документлар белешмәләренә туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы юридик зат, шәхси эшкуар ТР МК Баш ветеринария идарәсенә элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслый торган документларны өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының тиешенчә имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, ТР МК Баш ветеринария идарәсенә тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхәт ителми.

Вазыйфаи затлар юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны мәҗбүри тәртиптә карый. Зарури таләпләр бозылу очраклары булмаган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү акты төзи.

Әгәр элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслап тапшырылган аңлатмалаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң ТР МК Баш ветеринария идарәсе зарури таләпләр бозылу билгеләрен ачыкласа, яисә аңлатмалар булмаган очракта, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы, аны үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү үткәргәндә алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итү рөхсәт ителми. Мондый очракта документар тикшерү нәтиҗәсе «Планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлап җибәрү нигезенә туры киләчәк.

Күчмә тикшерү үткәрү зарурлыгы турындагы карарны ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) кабул итә.

Үтәү вакыты: тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәдә (боерыкта) һәм әлеге Регламентның 2.10, 2.13, 2.14 пунктлары нигезендә билгеләнгән вакыт эчендә.

Эш нәтиҗәсе: контрольлек буенча үткәрелгән чаралар, зарури таләпләр бозылу очралары булуын яки булмавын ачыклау, кирәк булганда планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

5.15. Планлы тикшерү уздырганда ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдаланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) куллану барлык юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү барышында гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү уздырылганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм шәхси эшкуарга белдерелә торган, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә) зыян салыну куркынычы барлыкка килүгә, шулай ук табигый һәм техноген

холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычына юл куймау күзлегеннән караганда үтәлеше аеруча әһәмиятле булган зарури таләпләргә кагылышлы сораулар була.

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү предметы тикшерү кәгазьләренә кертелгән сораулар исемлеге (контроль сораулар исемлекләре) белән чикләнә.

Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына теркәлә.

## ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.16. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы ике нөсхәдә Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган формада тикшерү актын төзи.

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә зарури таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне башкара:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

бетерү срокларын күрсәтеп һәм (яки) хайваннар тарафыннан кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә булган зыянны, хайваннарның гомеренә һәм сәламәтлегенә булган зыянны бетерү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирә;

ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә;

хайваннарга карата рәхимсез мөгамәлә өлешендә РФ Җинаять кодексының 245 статьясында каралган хокук бозу билгеләре ачыкланганда, прокурор исеменә гариза һәм тикшерү комитетына гариза төзи һәм тикшерү акты тапшыра.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

Контрольлек чарасы барышында контрольлек буенча чара уздыру объекты булып торган хуҗалык яисә башка төрле эшчәнлекнең законнардагы таләпләр бозылуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре ТР МК Баш ветеринария идарәсе компетенциясенә карамаса, ТР МК Баш ветеринария идарәсе мондый бозулар турында мәгълүматны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә тиеш.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә тегеп куя һәм аны ТР МК Баш ветеринария идарәсе архивына тапшырганчыга кадәр билгеләнгән тәртиптә саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле

вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тартуы турында имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерү ТР МК Баш ветеринария идарәсендәге делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның дәүләт күзәтчелеге кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта бу актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелә торган затка әлеге документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип исәпләнә. Актны тапшыру турында хәбәр һәм (яки) башкача раслама ТР МК Баш ветеринария идарәсендәге делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Үзләренә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә ТР МК Баш ветеринария идарәсенә тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта ТР МК Баш ветеринария идарәсенә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә дә җибәрелергә мөмкин.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр акт төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контрольлек чаралары төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын заказлы хат белән яки акт төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын формалаштыру урыны буенча ТР МК Баш ветеринария идарәсенең структур бүлекчәсендә саклау: аны билгеләнгән тәртиптә ТР МК Баш

ветеринария идарәсе архивына тапшырганчыга кадәр, норматив актларда билгеләнгән сроклар дәвамында.

Эш нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә тегеп куелган һәм формалаштыру урыны буенча ТР МК Баш ветеринария идарәсенең структур бүлекчәсендә билгеләнгән тәртиптә саклана.

5.17. Зарури таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү, шулай ук аларны кисәтү буенча чаралар күрә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

### ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.18. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең ветеринарлык эшчәнлеген оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштырылган планлы документлар тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.19. Вәкаләтле вазыйфаи зат 294-ФЗ номерлы федераль законның $13^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрләрнең бердәм реестрына тиешле мәгълүматны кертә.

## «ПЛАНЛЫ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.20. «Планлы күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасын башлап җибәрү өчен еллык план нигезендә юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы күчмә тикшерү уздыру срокларының килеп җитүе тора, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләрнең мөмкин булмавы да сәбәпче була ала:

1) юридик затның, шәхси эшкуарның ТР МК Баш ветеринария идарәсе карамагында булган документларындагы белешмәләрнең тулы һәм төгәл булуына инану;

2) юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контрольлек буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Планлы күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.9 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ, ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ, ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.21. Тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгеләү, планлы күчмә тикшерү үткәрү турында күрсәтмә (боерык) әзерләү, юридик затка, шәхси эшкуарга планлы күчмә тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү, үзкөйләнешле оешма әгъзасына тикшерү уздырылган очракта, – үзкөйләнешле оешмага хәбәр итү әлеге Регламентның 5.10-5.12 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ

5.22. Планлы күчмә тикшерү юридик зат урнашкан урын, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча һәм (яисә) аларның эшчәнлекләре фактта гамәлгә ашырылган урын буенча уздырыла.

5.23. Тикшерү объектына килеп җиткәннән соң вазыйфаи затлар тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

- ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының хезмәт таныклыгын күрсәтеп;

- юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен түбәндәгеләр белән мәҗбүри таныштырып:

планлы күчмә тикшерү билгеләнүе турында башлык (башлык урынбасары) боерыгы белән;

күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре белән;

күчмә тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре белән;

контрольлек чараларының төрләре һәм күләме белән;

күчмә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертлар составы, эксперт оешмалары вәкилләре белән;

аны үткәрү вакыты һәм шартлары белән;

- юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәрү турындагы боерыкның мөһер белән таныкланган күчермәсен кул куйдыртып тапшырып;

үтәү вакыты: тикшерү үткәрү урынына килеп җитү белән кичекмәстән.

5.24. Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча вазыйфаи затлар үзләренең вәкаләтләрен раслау максатларында ТР МК Баш ветеринария идарәсе турында, шулай ук экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә бурычлы.

Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча вазыйфаи затлар тикшерелергә тиешле затларны әлеге Регламент белән таныштырырга тиеш.

5.25. Тикшерү барышында вазыйфаи затлар:

- әлеге Регламентның 4 бүлегендә китерелгән, тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметлары белән бәйле документлардагы мәгълүматларны өйрәнә;

- юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә китерелгән зарури таләпләргә туры килү-килмәвен бәяли;

- күчмә тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән таныша, әгәр уздырылган документар тикшерү уздырганда мондый документлар бирелмәгән булса;

- кирәк булганда тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча юридик зат җитәкчесеннән, башка вазыйфаи затларыннан яисә тикшерелә торган затның вәкаләтле вәкиленнән язмача аңлатмалар соратып ала;

- тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча тапшырылган документларны, материалларны һәм аңлатмаларны анализлый һәм зарури таләпләрнең бозылуы (бозылу очракларының булмавы) турында карар кабул итә;

- хайваннарны карыйлар, юридик затлар, шәхси эшкуарлар эшчәнлеге барышында кулланыла торган объектларны (биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, бүлмәләрне, җиһазларны, транспорт чараларын, йөкләрне, башка объектларны) тикшерә;

- хайваннар белән эш итү өлкәсендә хокук бозуларны, шул исәптән фотога һәм видеога төшерү ярдәмендә дә, теркиләр;

- бозу фактларын раслаучы документларның күчермәләрен ясыйлар һәм билгеләнгән тәртиптә таныклыйлар (алга таба – раслаучы документлар);

- раслый торган документларның күчермәләрен теркәп, тикшерү актына зарури таләпләр бозылу фактлары турында белешмәләр кертә.

Экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре контрольлек буенча киләсе чараларны уздыра:

- хайваннарның йогышлы һәм инвазион авырулар белән авырып китү сәбәпләрен өйрәнәләр;

- йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асраганда һәм алардан файдаланганда ваемсызлык аркасында хайваннарның үлү сәбәпләрен өйрәнәләр;

- хайваннарның йогышлы чирләре, агулану очраклары һәм башка төрле массакүләм авыру очракларының барлыкка килү һәм таралу сәбәпләрен ачыклыйлар;

- карантин кертү режимының дөрес булу-булмавын һәм йогышлы авыруларга каршы көрәшнең башка кагыйдәләрен билгелиләр.

Зарурлык булганда, тикшерүне уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар әлеге Регламентның 10 пунктының 1.8 пунктчасы таләпләре нигезендә, билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән электрон формада да, документлар һәм (яки) мәгълүмат сората һәм ала.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.10, 2.13, 2.14 пунктлары нигезендә.

Эш нәтиҗәсе: контрольлек буенча уздырылган чаралар, зарури таләпләрне бозу очраклары булуын яки булмавын ачыклау.

5.26. Планлы тикшерү уздырганда ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдаланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) куллану барлык юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү барышында гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү уздырылганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм шәхси эшкуарга белдерелә торган, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә) зыян салыну куркынычы барлыкка килүгә, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычына юл куймау күзлегеннән караганда үтәлеше аеруча әһәмиятле булган зарури таләпләргә кагылышлы сораулар була.

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү предметы тикшерү кәгазьләренә кертелгән сораулар исемлеге (контроль сораулар исемлекләре) белән чикләнә.

Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына теркәлә.

5.27. Әгәр шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, юридик зат җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының башка төрле, тикшерү үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүе мөмкин булмаса, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзи. Бу очракта ТР МК Баш ветеринария идарәсе, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, планлы күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

## ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.28. Җаваплы башкаручы үткәрелгән контрольлек чаралары нигезендә РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә тикшерү актын төзи.

Тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлә:

үткәрелгән лаборатор тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизаларның беркетмәләре яки бәяләмәләре (кирәк булганда);

юридик затның, шәхси эшкуарның зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләреннән аңлатмалар;

зарури таләпләрне бозу фактларын раслаучы документлар;

Россия Федерациясе законнарында рөхсәт ителгән дәлилләрне теркәү ысуллары белән алынган, ачыкланган бозулар буенча фото-, видео- һәм башка материаллар;

тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә теге куя һәм аны ТР МК Баш ветеринария идарәсе архивына тапшырганчыга кадәр билгеләнгән тәртиптә саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тартуы турында имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерү ТР МК Баш ветеринария идарәсендәге делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта бу актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелә торган затка әлеге документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип исәпләнә. Актны тапшыру турында хәбәр һәм (яки) башкача раслама ТР МК Баш ветеринария идарәсендәге делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның бәяләмәсен алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чаралары тәмамланганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), әлеге документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда белдерү һәм (яисә) әлеге документның алынуына башкача дәлилләмә тикшерү актының ТР МК Баш ветеринария идарәсендә саклана торган дело нөсхәсенә теркәп куела.

Үзләренә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган

бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә ТР МК Баш ветеринария идарәсенә тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта ТР МК Баш ветеринария идарәсенә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә дә җибәрелергә мөмкин.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр акт төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контрольлек чаралары төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын заказлы хат белән яки акт төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын формалаштыру урыны буенча ТР МК Баш ветеринария идарәсенең структур бүлекчәсендә саклау: аны билгеләнгән тәртиптә ТР МК Баш ветеринария идарәсе архивына тапшырганчыга кадәр, норматив актларда билгеләнгән сроклар дәвамында.

Эш нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә тегеп куелган һәм формалаштыру урыны буенча ТР МК Баш ветеринария идарәсенең структур бүлекчәсендә билгеләнгән тәртиптә саклана.

5.29. Зарури таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү, шулай ук аларны кисәтү буенча чаралар күрә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

### ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.30. Җаваплы башкаручы юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) үткәрелгән планлы күчмә тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының атамасы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы белешмәләрне үз эченә

алган язуны терки, шулай ук тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Эш нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) үткәрелгән планлы күчмә тикшерү турында теркәлгән язу.

5.31. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны планлы күчмә тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең ветеринария эшчәнлеген оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштырылган планлы күчмә тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.32. Вәкаләтле вазыйфаи зат 294-ФЗ номерлы федераль законның $13^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрләрнең бердәм реестрына тиешле мәгълүматны кертә.

## «ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.33. Әлеге Регламентның 2.19 пунктында күрсәтелгән очраклар «Планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

«Планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасы түбәндәге гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

- тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;
- вазыйфаи затның дәлилләнгән күрсәтмәсен әзерләү (кирәк булганда, тикшерү әлеге Регламентның 2.19 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча үткәрелгән очракта) (алга таба – вазыйфаи затның дәлилләнгән күрсәтмәсен әзерләү);
- тикшерү уздыру турында күрсәтмә (боерык) рәсмиләштерү;
- юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү үткәрү хакында хәбәр итү;
- тикшерүне үткәрү;
- тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү;
- тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру.

### ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛГАН ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.34. Әлеге Регламентның 2.19 пунктындагы 2, 3 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгән очракта, Бүлек башлыгы, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары йөкләмәсе нигезендә юридик затны, шәхси эшкуарны тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затларны, җаваплы башкаручыны билгели.

Әгәр әлеге Регламентның 2.19 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез тикшерүнең нигезе булып торса һәм әгәр ТР МК Баш ветеринария идарәсенә килгән мәгълүматны тикшерү зарурлыгы булса, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары йөкләмәсе буенча мәгълүматны алдан тикшерү срогы билгеләнә.

Үтәү вакыты: ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы, башлык урынбасары күрсәтмәсе кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге, җаваплы башкаручы.

Әлеге Регламентның 2.19 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез килеп туганда – элек бирелгән күрсәтмәнең үтәлү вакыты узган очракта, тикшерүне күрсәтмәне биргән җаваплы башкаручы гамәлгә ашыра.

ВАЗЫЙФАИ ЗАТНЫҢ ДӘЛИЛЛӘНГӘН КҮРСӘТМӘСЕН ӘЗЕРЛӘҮ

5.35. Әгәр тикшерү әлеге Регламентның 2.19 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча үткәрелсә һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсенә килгән мәгълүматны тикшерү зарурлыгы булса, вазыйфаи зат мәгълүматка башлангыч тикшерү уздыра һәм (яки), әлеге Регламентның 2.25-2.27 пунктларында бәян ителгән таләпләрне исәпкә алып, юридик зат, шәхси эшкуар белән үзара бәйләнешкә кермичә генә контрольлек чараларын уздыра.

Зарури таләпләр бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, әлеге Регламентның 2.19 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек күләмдә белешмәләр алынганда, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты, әлеге Регламентның 2.19 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле күрсәтмә әзерли һәм аны ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына, башлык урынбасарына юллый. Планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карарны ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы, башлык урынбасары кабул итә.

Үтәү вакыты: йөкләмәдә күрсәтелгән срок нигезендә.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.36. Җаваплы башкаручы:

- Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган формада юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздырылуы турында күрсәтмә (боерык) проектын әзерли;

ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) 294-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә әзерләнә;

- күрсәтмә (боерык) проектын имза салу өчен ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Үтәү вакыты: планнан тыш тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң бер эш көне эчендә, яки йөкләмәдә күрсәтелгән срокка ярашлы рәвештә.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш тикшерү үткәрү турында ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган күрсәтмә (боерык).

ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ
УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.37. Җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.47 пункты нигезендә юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү үткәрү турында хәбәр итә.

ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ

5.38. Планнан тыш документар тикшерү уздырылганда җаваплы башкаручы юридик зат, шәхси эшкуар документларында булган белешмәләрне бәяли, кирәк булганда, хат (дәлилле мөрәҗәгать) әзерли, әлеге Регламентның 5.14 пунктында бәян ителгән таләпләрне үтәп, юридик зат, шәхси эшкуар документларын һәм (яки) аңлатмаларын карап тикшерә.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ
АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.39. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматларны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.16 пункты нигезендә ике нөсхәдә Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган формада тикшерү актын төзи.

5.40. Зарури таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү, шулай ук аларны кисәтү буенча чаралар күрә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ
МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.41. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны планнан тыш документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең ветеринария эшчәнлеген оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштырылган планнан тыш документлар тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.42. Вәкаләтле вазыйфаи зат 294-ФЗ номерлы федераль законның $13^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрләрнең бердәм реестрына тиешле мәгълүматны кертә.

## «ПЛАННАН ТЫШ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.43. «Планнан тыш күчмә тикшерү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.19 пунктында күрсәтелгән очраклар, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаса да, нигез булып тора:

1) юридик затның, шәхси эшкуарның ТР МК Баш ветеринария идарәсе карамагында булган документларындагы белешмәләрнең тулы һәм төгәл булуына инану;

2) юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контрольлек буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.3 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла.

### ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛГАН ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.44. Тикшерү уздыруга вәкаләтле җаваплы башкаручыны, вазыйфаи затларны билгеләү әлеге Регламентның 5.34 пунктына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

### ВАЗЫЙФАИ ЗАТНЫҢ ДӘЛИЛЛӘНГӘН КҮРСӘТМӘСЕН ӘЗЕРЛӘҮ

5.45. Әгәр тикшерү әлеге Регламентның 2.19 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча үткәрелсә һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсенә килгән мәгълүматны тикшерү зарурлыгы булса, вазыйфаи зат мәгълүматка башлангыч тикшерү уздыра һәм (яки), әлеге Регламентның 2.25-2.27 пунктларында бәян ителгән таләпләрне исәпкә алып, юридик зат, шәхси эшкуар белән үзара бәйләнешкә кермичә генә контрольлек чараларын уздыра.

Зарури таләпләр бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, әлеге Регламентның 2.19 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек күләмдә белешмәләр алынганда, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты, әлеге Регламентның 2.19 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле күрсәтмә әзерли һәм аны ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына, башлык урынбасарына юллый. Планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карарны ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы, башлык урынбасары кабул итә.

Үтәү вакыты: йөкләмәдә күрсәтелгән срок нигезендә.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.46. Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсен (боерыгын) әзерләү әлеге Регламентның 5.36 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ
УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.47. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү үткәреләчәге турында, әлеге Регламентның 2.19 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган планнан тыш күчмә тикшерүдән кала, теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә дә, хәбәр итә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ТР МК Баш ветеринария идарәсенә элегрәк тапшырылган булса.

Юридик затка, шәхси эшкуарга карата әлеге Регламентның 2.19 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерү турында гариза Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган гарзинаның бертип формасына туры китереп төзелә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларына планнан тыш тикшерү үткәрелгән очракта, җаваплы башкаручы, планнан тыш күчмә тикшерү үткәргәндә аның вәкиленең катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, планнан тыш тикшерү үткәрү турында үзкөйләнешле оешмага хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерү башланырга кимендә егерме дүрт сәгать алдан.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздырылуы турында җибәрелгән хәбәр (һәм, үзкөйләнешле оешма әгъзасына тикшерү уздырылган очракта, үзкөйләнешле оешмага җибәрелгән хәбәр).

ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ

5.48. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү әлеге Регламентның 5.22-5.25 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәдә (боерыкта) һәм әлеге Регламентның 2.10, 2.13, 2.14 пунктлары нигезендә билгеләнгән тикшерү уздыру вакыты дәвамында.

Эш нәтиҗәсе: контрольлек буенча үткәрелгән чаралар.

5.49. Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү уздыру әлеге Регламентның 5.27 пунктында күрсәтелгән сәбәпләр аркасында мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы сәбәпләрен күрсәтеп, аны уздыруның мөмкин булмавы турында акт төзи һәм, әлеге Регламентның 5.27 пунктына туры китереп, гамәлләр башкара.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.50. Тикшерү актын төзү, тикшерү актын юридик затка, шәхси эшкуарга бирү әлеге Регламентның 5.28 пунктына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

5.51. Зарури таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү, шулай ук аларны кисәтү буенча чаралар күрә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.52. Җаваплы башкаручы юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) үткәрелгән планнан тыш күчмә тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының атамасы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы белешмәләрне үз эченә алган язуны терки, шулай ук тикшерү уздырган вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Эш нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) үткәрелгән планнан тыш күчмә тикшерү турында теркәлгән язу.

5.53. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны планнан тыш күчмә тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең ветеринария эшчәнлеген оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтында урнаштырылган планнан тыш күчмә тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.54. Вәкаләтле вазыйфаи зат 294-ФЗ номерлы федераль законның $13^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрләрнең бердәм реестрына тиешле мәгълүматны кертә.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАР, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАР БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШКӘ КЕРМИЧӘ КОНТРОЛЬЛЕК ЧАРАЛАРЫ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.55. ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан раслана торган, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга йөкләмә «Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыру» административ процедурасын башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

5.56. Биремнәрне рәсмиләштерү һәм аларның эчтәлеге, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларының нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан билгеләнә.

5.57. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып йөкләмәдә күрсәтелгән ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары тора.

5.58. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын үткәрү вакыты йөкләмәдә билгеләнә.

5.59. Йөкләмә түбәндәге зарури таләпләрнең бозылу билгеләре турында мәгълүматка нигезләнеп формалаштырыла:

а) гражданнарның, шулай ук шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләреннән һәм гаризаларыннан, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматыннан – хайваннар белән эш итү өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары таләпләренең бозылуы турында;

б) тикшерүләрнең, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәләр үтәлешен тикшерүләрнең актларында, башка төр башкарма документларда булган;

в) үз вәкаләтләре кысаларында ТР МК Баш ветеринария идарәсе гамәлгә ашыра торган мониторингны уздырганда алынган.

5.60. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларына түбәндәгеләр керә:

1) «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырылганда зарури таләпләр үтәлешен күзәтү;

2) хайваннар белән эш итү өлкәсендә юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге яки гамәлләре турында федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган башка Россия Федерациясе актлары нигезендә ТР МК Баш ветеринария идарәсенә тапшырылырга тиешле булган (шул исәптән федераль

дәүләт мәгълүмат системалары ярдәмендә дә) яки ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан (шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында да) юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган башка Россия Федерациясе актларында каралмаган йөкләмәләрне йөкләмичә алынырга мөмкин булган мәгълүматларга анализ ясау юлы белән зарури таләпләр үтәлешен күзәтү;

3) федераль законнарда билгеләнгән контрольлек чараларының башка төрләре һәм рәвешләре.

5.61. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары үткәрелгәндә вәкаләтле вазыйфаи зат:

1) юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлекләрен әзерли;

2) документларны һәм материалларны туплый;

3) документларны һәм материалларны эшкәртә һәм анализлый;

4) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын үткәрү нәтиҗәләре буенча документлар әзерли.

5.62. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә уздырылган контрольлек чараларының нәтиҗәләре буенча вәкаләтле вазыйфаи зат хисап рәсмиләштерә.

5.63. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын уздырганда зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланган очракта, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларны чикләү буенча чаралар күрә, шулай ук, әлеге Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү зарурлыгы булганда, ачыкланган бозулар турында мәгълүматлар белән, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына (башлык урынбасарына) язмача рәвештә дәлилләнгән күрсәтмә җибәрә.

5.64. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыру барышында зарури таләпләрне бозуга әзерләнү очраклары яки бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта, ТР МК Баш ветеринария идарәсе юридик затка, шәхси эшкуарга әлеге Регламентның 3.3, 3.4 пунктларына ярашлы рәвештә зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү җибәрә.

5.65. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә уздырылган контрольлек чараларының нәтиҗәләре ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне планлаштырганда һәм үткәргәндә кулланыла.

## «ФИЗИК ЗАТЛАРГА КАРАТА ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.66. Физик затларга карата дәүләт күзәтчелеге түбәндәгеләрне оештыру һәм үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла:

а) планлы (рейдлы) тикшерүләр;

б) планнан тыш документар һәм (яки) күчмә тикшерүләр.

5.67. Планлы (рейдлы) тикшерүләрне гамәлгә ашыру һәм планнан тыш документар һәм (яки) күчмә тикшерүләр үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.21, 2.22 пунктларында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

5.68. Физик затлар тарафыннан зарури таләпләр бозылу очракларын ачыклау максатында, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле затлары үз компетенциясе чикләрендә хайваннарның хуҗалары булган физик затлар тарафыннан хайваннар асрала һәм (яки) файдаланыла торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә яки территорияләргә, җир кишәрлекләренә, ял итү, туристлык, физик культура һәм спорт өчен файдаланыла торган һәм билгеләнгән территорияләргә, ваклап сәүдә итү һәм хезмәтләр күрсәтү урыннарына, хайваннарның күргәзмәләрен уздыру урыннарына планлы (рейдлы) караулар уздыра.

5.69. Планлы (рейдлы) караулар ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе яки боерыгы белән расланган план (рейд) йөкләмләре нигезендә үткәрелә.

5.70. План (рейд) йөкләмәсен һәм аның эчтәлеген рәсмиләштерү тәртибе, планлы (рейдлы) карау нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан билгеләнә.

5.71. План (рейд) йөкләмәсендә күрсәтелгән ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары планлы (рейдлы) карауны үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып тора.

5.72. Планлы (рейдлы) карауны уздыру вакыты план (рейд) йөкләмәсендә билгеләнә.

5.73. Планлы (рейдлы) карау уздырганда вәкаләтле вазыйфаи зат:

1) физик зат – хайваннар хуҗасы хайваннар асрый һәм (яки) хайваннардан файдалана торган яисә хуҗасыз хайваннарның тереклек итү урыны булган биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, бүлмәләрнең яки территорияләрнең, җир кишәрлекләренең, аларны тикшерү максатларында, исемлеген әзерли;

2) исемлек буенча урыннарны тикшерә;

3) хайваннарны визуаль тикшереп чыга;

4) үткәрелгән тикшерү барышында ачыкланган зарури таләпләр бозылу очракларын фотога, видеога төшерә;

5) зарури таләпләрне бозган затларны билгели;

6) планлы (рейдлы) карау нәтиҗәләре буенча документлар әзерли.

5.74. Рейдлы карау үткәрү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле зат хисап рәсмиләштерә.

5.75. Планлы (рейдлы) карау үткәргәндә зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланган очракта, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларны чикләү буенча чаралар күрә, шулай ук, әлеге Регламентның 2.22 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән нигезләр буенча физик затка планнан тыш һәм (яки) күчмә тикшерү билгеләү турында карар кабул итү зарурлыгы булганда, ачыкланган бозулар турындагы мәгълүматлар белән, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгына (башлык урынбасарына) язмача рәвештә дәлилле күрсәтмә җибәрә.

5.76. Планлы (рейдлы) карау үткәрелгәндә зарури таләпләрне бозуга әзерләнү очраклары яки бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта, ТР МК Баш ветеринария идарәсе физик затка әлеге Регламентның 3.3, 3.4 пунктларына ярашлы рәвештә зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү җибәрә.

5.77. Рейдлы карау нәтиҗәләре ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан планнан тыш тикшерүләрне планлаштырганда һәм үткәргәндә кулланыла.

5.78. Планлы (рейдлы) карауларны уздыру нәтиҗәләре буенча зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланганда, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) карары буенча әлеге Регламентның 5.82-5.88 пунктларында каралган тәртиптә физик затка карата планнан тыш документар һәм (яки) күчмә тикшерү үткәрү турында боерык чыгарыла.

5.79. ТР МК Баш ветеринария идарәсенә мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар физик зат – хайван хуҗасына карата тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

5.80. Физик затларга тикшерү үткәрү турында ул башланырга 15 көн алдан ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгының (башлык урынбасары) боерыгы күчермәсен кулга тапшыру турында белдерү белән почта аша заказлы хат итеп җибәреп яисә кул куйдыртып, физик затның кулына тапшыру юлы белән җиткерелә.

5.81. Физик зат тарафыннан хайванны (хайваннарны) асрау һәм (яки) алардан файдалану өчен кулланыла торган бина, төзелмә, корылма, бүлмә яки территория тикшерү уздыру урыны булып тора. Тикшерү хайванның хуҗасы булган физик зат яки аның вәкаләтле вәкиле катнашында үткәрелә.

5.82. Тикшерү уздырыр алдыннан ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи заты хезмәт таныклыгын күрсәтергә, физик затны (аның вәкаләтле вәкилен) тикшерү билгеләнүе турында ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе яки боерыгы белән, тикшерү уздыра торган вазыйфаи затларның вәкаләтләре, тикшерү уздыруның максатлары, бурычлары, нигезләре, сроклары һәм шартлары, контрольлек чараларының төрләре һәм күләмнәре белән, шулай ук тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертларның һәм эксперт оешмалары вәкилләренең составы белән таныштырырга тиеш.

5.83. Тикшерү уздырганда физик затларның хокуклары:

а) тикшерүне үткәргәндә катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

б) ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына караган мәгълүматны алырга;

в) тикшерү предметына караган документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшырырга;

г) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу, алар белән, шулай ук ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән, килешү яки килешмәү турында күрсәтергә;

д) тикшерү уздырганда ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының физик затның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләренә

(гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә.

5.84. Тикшерү барышында ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары, физик зат рөхсәте белән, хайванны (хайваннарны) асрау өчен кулланыла торган бинада, төзелмәдә, корылмада, бүлмәдә яки территориядә булырга һәм физик заттан тикшерү предметы һәм максатлары белән бәйле кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга хокуклы.

5.85. Тикшерү тәмамланганнан соң, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары ике нөсхәдә тикшерү акты төзи, аларның берсе физик затка (аның вәкаләтле вәкиленә) тапшырыла.

5.86. Физик затның (аның вәкаләтле вәкиленең) булмавы яки физик затның (аның вәкаләтле вәкиленең) тикшерү уздыру мөмкинлеген юкка чыгара торган гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә тикшерү уздыру мөмкинлеге булмаган очракта, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкинлеге булмавы сәбәпләрен күрсәтеп, тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи.

5.87. Тикшерү барышында ТР МК Баш ветеринария ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан РФ Җинаять кодексында җинаять дип таныла торган хайваннарга карата рәхимсез мөгамәлә очрагы ачыкланса, тикшерү актында тиешле язма теркәлә һәм акт күчермәсе билгеләнгән компетенция кысаларында чаралар күрү өчен хокук саклау органнарына җибәрелә.

5.88. ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затының законлы эшчәнлегенә комачаулау турындагы белешмәләр булган очракта, физик затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

## 6. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ҮТӘЛҮЕН ТИКШЕРЕП ТОРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

6.1. ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт вазыйфалары үтәлүен тикшереп тора, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт вазыйфалары тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тоту ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан башкарыла.

6.3. Әлеге Регламентка ярашлы рәвештә дәүләт күзәтчелеген үтәү чорлары, гамәлләрне башкару эзлеклелеге үтәлүгә, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының карарлар кабул итүенә агымдагы контрольлек ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары һәм ТР МК Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.4. ТР МК Баш ветеринария идарәсенең дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга агымдагы контроль ясарга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге, әлеге контрольне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы ТР МК Баш ветеринария идарәсе актлары нигезендә билгеләнә. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыру өчен

ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының вәкаләтләре ТР МК Баш ветеринария идарәсенең структур бүлекчәләре, дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары турындагы нигезләмәләрдә билгеләнә.

6.5. ТР МК Баш ветеринария идарәсе ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруның тулы һәм сыйфатлы булу-булмавына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыра. Планлы тикшерүләр – елга 2 тапкыр ешлыкта, планнан тыш тикшерүләр юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан, физик затлардан шикаятьләр кергән очракта үткәрелә.

6.6. ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хокуксыз дип танылган гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында юридик затларга, шәхси эшкуарларга, физик затларга китерелгән зыян, гражданлык законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, җитешмәгән табышны (алынмаган керемне) да кертеп, кире кайтарылырга тиеш.

6.7. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары административ процедураларны үтәү срокларын һәм тәртибен үтәү, кабул ителгән карарларның дөреслеге һәм нигезлелеге, кулланыла торган чараларның законлылыгы, аларны куллану тәртибен үтәү һәм кулланыла торган чараларның камилләштерелгән кагыйдәләргә туры килүе, хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның, физик затларның хокукларын саклау өчен җаваплы.

Дәүләт функцияләрен үтәү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә аларның вазыйфаи регламентларында беркетелә.

6.8. Үзләренә карата дәүләт күзәтчелеге гамәлгә ашырыла торган гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары, дәүләт функцияләрен башкарганда ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары эшчәнлеген контрольдә тотуның Россия Федерациясе законнарында каралган теләсә нинди рәвешләренә хокуклы.

6.9. Хайваннар белән эш итү өлкәсендә иҗтимагый контрольлек иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциясез башка оешмалар тарафыннан аларның уставлары нигезендә, шулай ук гражданнар тарафыннан 498-ФЗ номерлы федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 7. ТР МК БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫНА) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән гамәлләргә (гамәл кылмага) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белән мөрәҗәгать язма рәвештә, электрон документ формасында рәсмиләштерелергә тиеш.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шулай ук ТР МК Баш ветеринария идарәсенең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

7.2. ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында кабул ителгән яисә гамәлгә ашырылган карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмавы) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү предметы булып тора.

7.3. Судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять карауны туктатып тору яки караудан баш тарту нигезләре каралмаган.

Әгәр язмача шикаятьтә юридик затның атамасы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда), шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр бу шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасыз яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, ТР МК Баш ветеринария идарәсе шикаятьне анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга хокуклы. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьтә аның асылы буенча, элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә, инде берничә мәртәбә язмача җавап бирелгән сорау бәян ителсә һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы, ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле зат, әлеге шикаятьнең һәм элек җибәрелгән

шикаятьләрнең ТР МК Баш ветеринария идарәсенә яисә ТР МК Баш ветеринария идарәсенең шул бер үк вазыйфаи затына җибәрелгән булу шарты белән, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

ТР МК Баш ветеринария идарәсенә яки ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, ТР МК Баш ветеринария идарәсенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алган язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган ТР МК Баш ветеринария идарәсе рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә әлеге белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирүнең мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне ТР МК Баш ветеринария идарәсенә яисә аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.

7.4. ТР МК Баш ветеринария идарәсенә мөрәҗәгать итүчедән (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән яки почта юлламасы, электрон документ рәвешендә яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша мөрәҗәгать (шикаять) алынуы судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү процедурасын башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

7.5. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы. Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар ТР МК Баш ветеринария идарәсе адресына тиешле мөрәҗәгатьне язмача яисә электрон рәвештә җибәрергә тиеш. ТР МК Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затлары сорала торган белешмәләрне һәм документларны мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң 30 календарь көненнән артмаган чорда бирергә бурычлы.

7.6. Мөрәҗәгать итүченең шикаяте буйсынганлык буенча тиешле җитәкчегә тапшырыла.

ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлегенең вәкаләтле вазыйфаи заты гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләр ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлеге башлыгы тарафыннан карала.

ТР МК Баш ветеринария идарәсе территориаль бүлеге башлыгы гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләр ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан карала.

ТР МК Баш ветеринария идарәсе башлыгы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

7.7. Судка кадәр (судтан тыш) тәртиптәге шикаятьләр ТР МК Баш ветеринария идарәсе тарафыннан аларны теркәгәннән соң 30 календарь көне эчендә карала.

7.8. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, ә атап әйткәндә:

хезмәт тикшерүе барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә аларга карата чаралар күрү;

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле затларга карата кабул ителгән чаралар турында хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга, физик затка мондый чаралар кабул ителгән көннән соң ун календарь көне эчендә язмача рәвештә хәбәр итү;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга, физик затка, мондый карарны дәлилле рәвештә нигезләп, язмача рәвештә хәбәр итү юлы белән, хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән дәгъваны канәгатьләндермичә калдыру.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең фирма бланкында

Казан шәһәре «__» ____________ 20__ ел.

_______________________________________
Тикшерелә торган оешма атамасы
_______________________________________
Адрес

КҮРСӘТМӘ №

Минем тарафтан, ______________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
(күрсәтмә биргән затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

хайваннар белән эш итү өлкәсендә законнардагы таләпләр үтәлешен тикшерү буенча күчмә (планлы, планнан тыш) тикшерү уздырылды, түбәндәгегә карата:
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
(юридик зат атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тикшерү түбәндәге нигез буенча уздырылды: ____________________________________
_______________________________________________________________________________________
(дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы боерыгы, дата һәм №)

Тикшерү барышында катнашты(лар): ______________________________________________
_______________________________________________________________________________________
(тикшерү уздырганда катнашкан затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

Тикшерү барышында зарури таләпләр бозылуның түбәндәге очраклары ачыкланды:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 11 февралендәге 90 номерлы карарына таянып, шулай ук түбәндәгеләр нигезендә:

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

(карар, күрсәтмә, боерык, боерык, инструкция, кагыйдә атамасы)

Билгеләнгән срокларда күрсәтмә бирәм:_______________________________________

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

(ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча тәкъдимнәр, чаралар, үтәү сроклары)

Әлеге чараларны үтәү өчен җаваплы затлар:

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

(Фамилиясе, исеме, ата исеме, биләгән вазыйфа, телефон номеры)

Күрсәтмә _______ нөсхәдә төзелде.

Әлеге күрсәтмәнең үтәлеше турында 20___ елның «___» ____________ кадәр хәбәр итәргә.

Күрсәтмәгә карата судка, югары торучы дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, югары торучы вазыйфаи затка билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

Күрсәтмәне бирде

| ________________________ | ____________________ | ________________________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (тулы имза) |
| ________________________ | ____________________ | ________________________________ |

Күрсәтмәне алды

| ________________________ | ____________________ | ________________________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (тулы имза) |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламентына 2 нче кушымта

Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында
КИСӘТҮ

«____»_____________20___ №____________

______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(юридик зат атамасы, шәхси эшкуарның, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

1) Зарури таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр, әлеге таләпләрне күздә тоткан норматив хокукый актлар, шул исәптән аларның структур берәмлекләре:
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

2) Юридик затның, шәхси эшкуарның, физик затның нинди гамәлләре (гамәл кылмавы) зарури таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылуга китерә яки китерергә мөмкин булуы турында мәгълүмат:
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

3) Юридик затка, шәхси эшкуарга, физик затка зарури таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итү;
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________________

20__ елның «___»____________ кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенә кисәтүне үтәү турында белдерү җибәрергә тәкъдим итәм, анда түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

а) юридик зат атамасы, шәхси эшкуарның, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

б) салым түләүче – юридик затның, шәхси эшкуарның, физик затның индентификацияләү номеры;

в) юридик зат, шәхси эшкуар, физик зат адресына җибәрелгән кисәтүнең датасы һәм номеры;

г) кисәтүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүмат.

РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары белән расланган Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар белдерү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында белдерү кагыйдәләренең 7 пункты нигезендә, кисәтүне карау нәтиҗәләре буенча юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан кисәтүне җибәргән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына ризасызлыклар белдерелергә мөмкин *.

* Кисәтүгә карата булган ризасызлыкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) юридик зат атамасы, шәхси эшкуарның, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

б) салым түләүче – юридик затның, шәхси эшкуарның, физик затның индентификацияләү номеры;

в) юридик зат, шәхси эшкуар, физик зат адресына җибәрелгән кисәтүнең датасы һәм номеры;

г) юридик затның, шәхси эшкуарның, физик затның зарури таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылуга китерә торган яки китерергә мөмкин булган кисәтүдә күрсәтелгән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата позицияне нигезләү.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы ____________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламентына 3 нче кушымта

ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕҢ БЛОК-СХЕМАСЫ



Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә йорт хайваннарын һәм хуҗасыз хайваннарны асрау һәм алардан файдалануга карата таләпләр үтәлеше өлешендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламентына
4 нче кушымта

ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРГАНДА ВЕДОМСТВОАРА МӘГЪЛҮМАТИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЫСАЛАРЫНДА ТР МК БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ ТАРАФЫННАН ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАР БЕЛӘН ЭШ ИТҮЧЕ БАШКА ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫННАН, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫННАН ЯИСӘ ОЕШМАЛАРДАН СОРАТЫЛА ТОРГАН ӘЛЕГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

| Соратыла торган документның аталышы һәм (яисә) соратыла торган мәгълүмат | Документлар һәм (яисә) соратыла торган мәгълүматлар белән эш итүче дәүләт органы |
|---|---|
| Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Квалификациясе алынган затлар реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |